БҮРЕ һәм кәҗә бәтиләре



МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

А. Толстой

ВОЛК И СЕМЕРО КОЗЛЯТ

(на татарском языке)

С. Сабиров тәрҗемәсе

Редакторы *Р. Вәлиева*

Тышлык художнигы *П. Григорьев*

Т. Козулина рәсемнәре

Художество редакторы *Э. Е. Дьячкова*

Техник редакторы *В. Н. Галкина*

Корректоры *Р. С. Хамидуллина*

Производствога бирелде 13|V-59 ел. Басарга кул куелды 4|VIII-59 ел. Кәгазь форматы 70x92 1|16 Учет.-изд. 0,75 табак. Басма табак 1,0 (1,17). Табакта 16416 знак. Заказ К-233. Тираж 20 000 экз. Бәясе 35 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19, 1959 ел.

БҮРЕ
һәм
КӘҖӘ БӘТИЛӘРЕ



А. ТОЛСТОЙ эшләнешендә рус халык әкияте

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1959



Борын-борын заманда бер кәҗә булган. Аның бәтиләре дә бар икән. Кәҗә ефәк кебек йомшак үлән ашарга, салкын чишмә суын эчәргә урманга барып йөри икән. Әниләре китте исә, бәтиләре ишекне биклиләр дә үзләре беркая да чыкмыйлар икән.



Әйләнеп кайткач, әниләре ишекне шакылдата-шакылдата:

— Бәтиләрем минем, балакайларым!
Ачыгыз, ишекне, тизрәк, ачыгыз!
Сезне сагынып әнкәгез кайтты —
Сезгә күп итеп сөт алып кайтты, —

дип җырлый икән.

Шуннан кәҗә бәтиләре ишекне ачып, әниләрен кертәләр. Әниләре аларны ашата, эчертә

дә тагын урманга чыгып китә икән. Ә бәтиләр ишекне бик ныклап бикләп калалар икән.

Бервакыт шулай кәҗәнең җырын бүре ише-





теп алган. Кәҗә чыгып китүгә, бүре өй янына йөгереп килгән дә калын тавыш белән:

— Сөекле балакайлар сез,
Бик акыллы бәтиләр!
Ачыгыз ишекне, тизрәк ачыгыз,
Сезне сагынып әнкәгез кайтты,
Сезгә күп итеп сөт алып кайтты,—

дип кычкырган.

Кәҗә бәтиләре аңа болай дип җавап биргәннәр:


— Ишетәбез ишетүен дә, тик бу безнең



әнкәй тавышы түгел шул. Безнең әнкәбез нечкә тавыш белән җырлый, аннары ул болай такмакламый да.




Шуннан бүре нишләсен инде. Нечкә тавыш белән җырлау өчен, тимерче алачыгына барып, бугазын чүкеп бирергә кушкан. Тимерче чүкеп биргәч, бүре тагын өй янына чабып килгән дә куаклыкка яшеренгән.



Менә кәҗә кайтып җиткән.

— Бәтиләрем минем, балакайларым!
Ачыгыз ишекне, тизрәк ачыгыз!
Сезне сагынып әнкәгез кайтты —
Сезгә күп итеп сөт алып кайтты,—

дип ишекне шакылдата башлаган ул.



Кәҗә бәтиләре, әнкәләрен кертеп, бүренең килүен, аларны ашарга теләвен сөйләп биргәннәр.

Кәҗә үзенең бәтиләрен ашаткан, эчерткән дә:

— Әгәр дә өй янына кем дә булса килеп, калын тавыш белән, кертегез дип сораса, ишекне ачмагыз, беркемне дә кертмәгез, — дип бик нык кисәтеп әйтеп калдырган.

Кәҗәнең китүе булган, бүре тагын өй янына килгән дә нечкә генә тавыш белән:



— Бәтиләрем минем, балакайларым!
Ачыгыз ишекне, тизрәк ачыгыз!
Сезне сагынып әнкәгез кайтты —
Сезгә күп итеп сөт алып кайтты, —

дип такмакларга керешкән.



Кәҗә бәтиләре ишекне ачканнар. Бүре өйгә атылып кергән дә кәҗә бәтиләренең барысын да ашап бетергән. Тик бер бәти генә мич эченә яшеренеп калган.



Кәҗә кайткач, күпме генә эдәншсә дә, такмакласа да, һичкем дә аңа җавап бирмәгән.

Караса — ишек ачык, өйгә керсә — анда берәү дә юк. Мичне ачып караса, шуннан бер бәтиен тапкан. Башына шулкадәр авыр кайгы төшкәнен белгәч, кәҗә скамьяга утырган да такмаклый-такмаклый еларга тотынган:



— Их, сез, минем балакайларым,
Их, сез, минем бәтиләрем!
Ни дип кенә ишекне ачтыгыз,
Явыз бүрегә азык булдыгыз?



Бүре моны ишеткән дә, өйгә кереп, кәҗәгә болай дигән:


— Нигә син бу гаепне миңа ягасың, кодача? Мин синең бәтиләреңне ашамадым! Ташла кайгыруыңны! Әйдә, урманга чыгып, бераз йөреп керик!

Шуннан болар урманга киткәннәр. Ә урманда бер чокыр булган, ул чокырда ут янып тора икән. Шунда барып җиткәч, әйткән, ди, кәҗә бүрегә:

— Әйдә, бүре, сынашып карыйк, кайсыбыз чокыр аша сикереп чыга алыр икән, — дигән, ди.

Менә болар сикерешә башлаганнар. Кәҗә чокырны сикереп чыккан. Бүре дә сикереп караган икән дә, утлы чокырга барып төшкән.

Кызудан бүренең корсагы шартлаган. Аннан кәҗә бәтиләре атылып килеп чыкканнар. Алар һәммәсе дә исән-саулар икән, шунда ук әниләре янына сикереп менгәннәр. Шулай итеп болар әүвәлгечә үк рәхәтләнеп бергә яши башлаганнар, ди.



35 тиен



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1 9 5 9